“Россия династияләре “

укучыларның регионара иҗади һәм проект эшләре конкурсына

# “Укытучылар династиясе” юнәлешендә фәнни- эзләнү эше:

# “Мөгаллимнәр-нәселебез горурлыгы!”

Эшне башкарды: ТР Арча муниципаль районы Г. Камал исемендәге Сикертән төп гомуми белем мәктәбенең 3 класс укучысы Гарипов Әмир Ленар улы.

Фәнни җитәкчесе: беренче категорияле башлангыч класслар укытучысы Гарипова Алсу Альберд кызы.

2018 нче ел

## Эчтәлек

**I. Кереш өлеш.** Мөгаллимнәр - иң зур хөрмәт һәм мактауга лаек кешеләр!

**II. Төп өлеш.** Нәсел шәҗәрәсен барлау.

1. Хәсән Зиннәтулла улы Абдуллинның тормышы.

2. Хәсән карый балаларының югары белемгә ирешүләре.

3. Аның нәселен мәгърифәтле оныклары дәвам итә.

**III. Йомгаклау.**

**IV. Кулланылган әдәбият исемлеге.**

**Тикшерү эшенең темасы: “**Мөгаллимнәр- нәселебез горурлыгы!”

**Теманың актуальлеге:** үземнең нәсел җебен өйрәнеп,киләчәк буынга җиткерү; өлкәннәргә карата хөрмәт хисләре тәрбияләү, кызыксыну дәрәҗәләрен арттыру.

**Эшнең максаты**: Укытучылар династиясе тарихын тикшерү, материаллар туплау, нәтиҗә чыгару.

**Тикшерү объекты:** Хәсән карый нәселе.

**Тикшерү методлары:** эврестик ысул- эзләнү, тикшеренү һәм нәтиҗә чыгару.

**Алымнар:** фәнни әдәбият белән танышу, нәселебездәге өлкән кешеләрдән тарих сөйләтү, язмаларны редакцияләү, фотога төшерү.

## I. Кереш өлеш. Мөгаллимнәр - иң зур хөрмәт һәм мактауга лаек кешеләр!

Балачагым

хиатирәсе итеп

Саклыйм әлифбалы дәфтәремне

Шул дәфтәрне ачкач, күз алдына китерәм

Укытучым белән мәктәбемне.

Э.Мөәминова

Җир йөзендә бик күп һөнәрләр бар. Шулар арасында укытучы һөнәре бик авыр һәм җаваплы, ләкин иң дәрәҗәле һөнәрләрнең берсе булып тора. Безнең уйлавыбызча, укытучыдан башка дөньяны күз алдына да китереп булмас иде. Чөнки җир йөзендәге барлык һөнәр кешеләренә дә бер олугъ зат - Укытучы белем һәм тәрбия биргән. Мөгаллимнәр ак кәгазь бите кебек сабый күңеленә беренче орлыкны сибәләр. Аларның шытып чыгуы өчен шартлар тудыралар, үскәнен күзәтәләр. Соңыннан шул уңышны җыеп алуына куанучы кешеләр дә бит алар. Җыеп кына әйткәндә, иң зур хөрмәт һәм мактауга лаек кешеләр. Без юктан гына укытучылар династиясе турында эзләнү- тикшерену эшенә керешмәдек.

“Үткәнен белмәгән халыкның киләчәге юк”,- ди халык. Нәсел-ыру тарихлары белән кызыксыну дөньядагы күп халыкларга таныш. Һәр мөселман үзенең әтисе һәм әнисе ягыннан җиде буын бабасын белергә тиеш була. Без дә еш кына үзебезнең нәселебез турында уйланабыз. Сулар ага - ярлары кала. Гомер үтә – эшләре кала. Кешеләр күчә - нәселе кала,эшләгән эшләре, кылган яхшылыклары, изгелекләре җирдә, киләчәк буыннар хәтерендә, күңелендә кала.

Мин, Гарипов Әмир Ленар улы, Г. Камал исемендәге Сикертән төп гомуми белем мәктәбенең 3 нче классында укыйм, әнием ягыннан нәсел

җепләрен барлыйм. Чөнки әнием - укытучы. Ул еш кына миңа тарих сөйләргә ярата, ә аның туганнары арасында укытучылар күп.

**Эзләнү эшенең максаты:**

- укытучылар династиясе саналган туганнарымның истәлекләрен туплау;
- музейның “Укытучылар династияләре” бүлеген тулыландыру;

**Эзләнү эшенең бурычлары:**

- укытучы хезмәтенә хөрмәт һәм мәхәббәт хисләре тәрбияләү;
- ветеран укытучылар һәм аларның династияләрен өйрәнү буенча белемнәрне арттыру;
- эзләнү эшләрен алып бару күнекмәләрен булдыру һәм ныгыту.

**II. Төп өлеш. Нәсел шәҗәрәсен барлау.**

**Эзләнү эшен оештыру.**

Иң беренче эш итеп без әнә шул материалларны өйрәндек. Туганнарыбызның өйләрендә булып, истәлекләрен язып алдык, фотосурәтләрен җыйнадык. Нәсел шәҗәрәсенә дә күз салдык. Нәсел агачыннан күренгәнчә, горурланып сөйләрлек кешеләребез бик күп булган. Безнең нәсел җебе тирә-якта мәгърифәтлелеге белән танылган Хәсән муллага килеп тоташа, шулай ук алар арасында фән эшлеклеләре, профессорлар, язучылар да бар икән.

Арча районы авылларында халык хәтерендә зур мулла-хәлфә булып дан казанган шәхесләр бар. Совет власте елларында аларга мөнәсәбәт кискен үзгәрә. “Дин – халык өчен агу” дигән лозунг белән коралланып, аларны эзәрлекләү башлана. Ә бит татар муллалары, бер яктан Аллаһыга, икенче яктан кешеләргә хезмәт иткәннәр, халыкка дин-иман нурын тараткannar, үзләре дә белем чыганагы булганнар. Бөек галим, шагыйрь, философ Утыз Имәни, Кандалыйлар, һ.б. мулла булганнар.

Мөселман татарларының рухани тәрбиячеләренә - муллаларга булган ихтирамы һәм аларның ирешкән казанышлары турында күренекле немец галиме ( Казанда яшәгән), галим-этнограф Карл Фукс мөһим бәяләмә язып калдырган. «Татар муллаларына тиешле югары бәя бирергә кирәк. Алар бик уңышлы итеп мәгърифәтне шәһәрләрдә генә түгел, ерак авылларда да халыкка тараталар. Һәр мулла диярлек мәктәп тота, әз генә түләү белән

малайларны һәм кызларны гарәп теленә өйрәтә, Коръән укый һәм тәфсирли (аңлата) – аның өйрәтмәләрен белдерә».

Карл Фуксның бу язмалары 1844 нче елда ук дөнья күрә, әмма хәзер дә бик мөһим.

**1. Хәсән Зиннәтулла улы Абдуллинның тормышы.**

Бу бик хаклы бәяләмәне Арча районының Сикертән авылда 1919-1949 нчы елларда мулла булган Хәсән Зиннәтулла улы Абдуллинга да бирергә була. Ул тирә-як авылларда Хәсән карый исеме белән дан казанган. Ул Корьәнне яттан белгән, укыган, шуңа күрә дә аңа, белемле хәлфә булганы өчен дә, тирән ихтирам белән караганнар.

Ул Казанда 1855 нче яисә 1865 нче елларда туа. Әтисе Зиннәтулла Абдуллин Башкортстанның Дуртиле районына керә торган Юкәле Күл исемле татар авылында туган. Казанга килеп укыган һәм шунда калып, гомерен хәлфә булып үткәргән. Анын өч баласы була : Хөсәен (? - 1919), Рабига (? - 1918) – язучы Фатих Әмирханның ( 1886 – 1929 нчы ел) әнисе, Хәсән Карый. Димәк, Хәсән (Абдуллин) язучы Фатих Әмирханның абыйсы. Хәсән карый Казанда мәдрәсә тәмамлаган, Зәңгәр мәчеттә имам булып эшли. Ул Чистай өязендәге Дума авылында мулла булган Тахтамышев Сибгатулланың Шәмселхәят исемле кызына өйләнә. Аның бер улы – татар язучысы Нәҗип Думави. Димәк, Шәмселхәят аның апасы. 1906 нчы елда аңа, имам буларак, мәхәллә байлары йорт салалар (1906 нчы – 1912 нчы елга хәтле архивта документы бар). Ул Тукай урамындагы 21нче йорт була (колхоз базары янында, 2010 нчы елда сүтелде).

Шулай итеп,татар әдәбиятына ике зур язучы биргән бу ике нәсел никах аша туганлаша.

Әмма, авыр еллар фаҗигалар китерә. Бу никахтан дүрт бала туа: Габдрахман (1910 нчы ел) , Сәгадәт, Гайшә, Зәйнәб. Ул – дүртенче бала , 1918 нче елда Казанга чехлар бәреп кергән көздә туа. Атышлар, сугышлар, алты айдан сугышлардан соң Казанга кызыл Армия килә. Хәлфә, укытучы, мулла булган Хәсән карыйга үзен чакырган Сикертән авылына мулла булып күчү бик кирәк

була. Ул йортын ташлап күчә. Әмма анда, кечкенә Зәйнәбкә 1 яшь тулганда, гаилә анасы Шәмсихәят  һәм абыстай кызлары Сәгадәт һәм Гайшә тиф авыруыннан үлеп китәләр.  1 яшь тулмаган Зәйнәбне мәрхәмәтле Сикертән хатыннары чиратлап имезәләр, шулай исән кала. Хәсән карый әнисез калган ике балага ана кирәк дип, күрше авылдан Сәләхетдин мулланың тол калган кызы Хәдичә абыстайны, кечкенә баласы Мөнирә белән, 1919 нчы елда никахлап ала.

Хәсән карый мулла вазыйфаларын үти, кырыс, таләпчән хәлфә буларак  дан казана.  Гаиләдә тагын өч бала туа, -  Өммегөлсем, Зөфәр, Мәрьям.

Зур гаиләдә  балалар тырыш, эшчән булып үсәләр. Кызлар кул эшләре , шәл бәйләүләр белеп, мәктәптә тырышып укыйлар.  Зәйнәб 5 класста ук Ликбез мәктәбендә  олы яшьтәгеләрне укытып йөри.

Әмма дин эшлекләренә кире караш гаиләнең тыныч тормышына янә зур авырлыклар китерә. Олы яшьтәге Хәсән карыйны репрессиялиләр, дин әһелләрен раскулачить дигән әмер белән  кечкенә балаларны үстерүче гаиләнең 28 нче, 30 нчы, 1933 нче елларда бар әйберләрен  конфискацияләп алып чыгалар. (Моны архив материаллары яза). Ахырдан аларны өйдән куып, чит кеше мунчасына урнаштыралар. Әмма, авыл халкы, безгә укытучы мулла кирәк дип, аларны арбага утыртып, бар халык җигелеп, өйләренә кайтаралар. (Аның кызлары шулай сөйли иде).

## 2. Хәсән карый  балаларының  югары белемгә ирешүләре.

Өйдә нык тәрбия алган балалар эшчән, тырыш булып үсәләр. Инде тарихтан билгеле булганча, татар зыялылары, мәгърифәтчеләре, язучылары чыгышлары белән күбесе муллалар гаиләсеннән була. Габдулла Тукай, Гаяз Исхакый, Атилла Расих, Галимҗан Ибрагимов  һ.б.

Авыр сугыш елларындаХәсән карый балалары да ачлыкта. Зөфәр улларын сугышка алгач та, кыз балалары Арча педучилищесында укыйлар, укытучы булалар. Әти-әниләре ярдәм итәргә  тырыша.

Педучилищедан соң, югары белемгә омтылалар, аңа ирешәләр. Өммегөлсөм география факультетын гел “5” кә тәмамлый һәм Мәгариф министрлыгында эшли.

Мәрьям рус теле һәм әдәбияты бүлеген шулай ук тәмамлап, 1944-1951 нче елларда Сикертән җиделлык мәктәбендә рус теле укытучысы һәм укыту бүлеге мөдире булып, 1952-1956 нчы елларда  Арча районында инспектор (Чуриледә),1956-1959 нчы елларда Арча урта мәктәбендә директор урынбасары булып эшли, 1987 нче елдан башлап,  Казанда Укытучылар белемен күтәрү һәм яңадан әзерләү институтында (ТИУУ,ИПКРО) профессор булып, ике телдә лекцияләр сөйләп, ил буенча мәктәпләрдә  укытучылар белемен күтәрә.кабинет мөдире, доцент, профессор вазыйфаларын башкара. Шушы елларда ул татар мәктәпләренең хәзерлек сыйныфлары өчен рус теле буенча, 2-4 нче сыйныфлар өчен әдәби уку программалары төзи. Аның методик кулланмалары 1971 нче елдан башлап нәшер ителә башлый.

Хәсәнова Мәрьям Хәсән кызы 60 ел гомерен мәгариф хезмәтенә багышлаган. Ул төзегән дәреслекләр, белем бирүдә ярдәмчел китаплар бихисап. Мәрьям Хәсән кызы – 1992 нче елдан башлап, Санкт-Петербургта чыга торган рус теле дәреслекләре авторларының берсе. Аның аерым китаплары түбәндәгеләр:”Аз комплектлы башлангыч мәктәпләрдә укыту-тәрбия эшен оештыру үзенчәлекләре”(1967), “Диктантлар җыентыгы”(1976, 1990), “1-3 нче сыйныфлар өчен изложениеләр җыентыгы” (1983).

Хөкүмәтебез Мәрьям Хәсән кызының фидакарь хезмәтен югары бәяли. Ул “СССРның мәгариф отличнигы”, “РСФСРның халык мәгарифе отличнигы”, 1968 нче елдан “Татарстан мәктәбенең атказанган укытучысы”, “За образование” күкрәк билгесе иясе.

Зәйнәб Түбән Новгородта тормышка чыга, укытучы булып 35 ел эшләп ялга чыга, өч бала үстерә. Аларның белем алуларына әниләре Хәдичә абыстай  ярдәм итә.  Зәйнәбкә аның үз әнисе түгеллеген үскәнче әйтмиләр, шундый олы җанлылык була ул анада. Хәсән карый сугыш беткәч, 1944 нче елда хатыны тәрбиясендә дөньядан китә. Бу гаиләдә уллары Зөфәр дә фаҗига

кичерә, 37 яшьтә улә. Өч баласы кала.  Бу турыда язучы М.Мәһдиевнең “Ачы тәҗрибә” китабында укырга була. Ул үзе дә репрессияләнгән мулла гаиләсеннән.

Хәсән карыйны, дингә караш үзгәргәч, 1994  нче елда реабилитациялиләр. Аның нәселен мәгърифәтле оныклары дәвам итә.  Алар арасында намуслы төрле  өлкәдә эшләүче  хезмәткәрләр, укытучылар, фән кандидатлары, докторлары, мәктәп директорлары, балалар тәрбиячеләре, тәрҗемәчеләр бар. Алар халыкка, татар телен үстерүгә,милләткә хезмәт иткәннәр, файда китергәннәр. Хәсән карый исеменә тап төшермәгәннәр.

Авылдашлары, туганнары, Сикертән авылында төп нигезгә Хәсән мулла исемен мәңгеләштерү уңаеннан, истәлек-музей салдылар, җәйгә музейны ачу тантанасы күтелә.

### 3. Аның  нәселен мәгърифәтле оныклары дәвам итә.

Бүгенге көндә  әтиләре, бабалары Хәсән карый күрсәткән  мәгърифәт юлын дәвам итүчеләр:

Башкурова-Садыйкова Айсылу Хөсәен кызы (Зәйнәб апа кызы) укытучылар гаиләсендә тәрбияләнеп үсә.1964-1965 нче елларда Казан шәһәренең Идел буе районында 80 нче мәктәптә химия кабинетында лаборант булып эшли.1963-1968 нче елларда Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетында укый, “рус теле һәм әдәбияты укытучысы” дигән белгечлек алып чыга. 1972-1977 нче елларда Татарстан Архив идарәсе Казан Үзәк архивында фәнни хезмәткәр булып эшли. 1977 нче елдан СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының әдәби редакторы, аннан өлкән редакторы. 1992 нче елда Филология фәннәре кандидаты дигән гыйльми дәрәҗә алу өчен диссертация яклый. 2003 нче елда “Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре” дигән мактаулы исем бирелә. 2005 нче елдан институтның баш фәнни хезмәткәре.

Зиннәтуллина Зөлфия Гариф кызы (Мәрьям Хәсәновнаның кызы) да укытучылык эше буенча китә. Бүгенге көндә ул институтта чит телләр бүлегендә студетларга белем бирә.

Җәләлиева( Хәсәнова) Рәмзия Зөфәр кызы Казан дәүләт педагогика институтының тарих филологиясе факультетының татар һәм рус теле бүлегенә укырга керә. (1977-1983). Аннан  Арча районы Штерә мәктәбендә 1 ел эшли. 1984 нче елда Сеҗе урта мәктәбенә эшкә кайта. Башта тарих, рус теле фәннәреннән укыта. 5 ел педагог- оештыручы булып, 5 ел укыту- тәрбия эшләре буенча директор урынбасары булып эшли. 2000 нче елдан башлап татар теле укытуга күчә. “Өлкән укытучы”, “Укытучы-методист”, “Россия Федерациясенең мактаулы мәгариф хезмәткәре”исемнәренә лаек була.  2013 нче елдан лаеклы ялга чыга.

**III. Йомгаклау**.

Менә без үзебезнең укытучылар династиясе белән таныштырып  чыктык. Нәсел агачы- шәҗәрәне барлаганда, зур горурлык хисләре кичердек. Гомерләрен мөгаллимлек эшенә багышлаган, бездә дә бу эшкә мәхәббәт уяткан әби-бабаларыбызның, абый-апаларыбызның тормыш юллары бездә соклану һәм кызыксыну уятты. Дистә еллар буена эстафета булып күчә барган әлеге һөнәргә безнең гаиләнең мәхәббәте әле дә сүнми, сүрелми. Без үзебезнең нәкъ шушы хөрмәтле, затлы нәселдән булуыбыз белән чын күңелдән горурланабыз. Чыннан да, бар нәрсәнең башлангычы - Укытучы кулында. Укытучыга да, атаклы галимгә дә, төзүчегә дә белемне укытучы бирә.

Минем әнием Гарипова Алсу Альберд кызы (рәс. 4)  да бүгенге көндә үз эшенең остасы, бу һөнәрдән башка тормышын күз алдына да китерә алмый. Ул 15 ел башлангыч класслар укытучысы булып эшли. Хезмәт юлын Арча районы Гөберчәк авылында башлап җибәрә, хәзерге вакытта Г. Камал исемендәге Сикертән төп гомуми белем мәктәбендә эшли. Ул үз эшен яратып башкара. Киләчәктә без, аның балалары да,үзебезнең династия эшен дәвам итәрбез дип уйлыйбыз.



(рәс.1)



(рәс.2)



(рәс.3)



(рәс.4)

**Кулланылган әдәбият:**

1. Марсель Әхмәтҗанов. Фатих Әмирхан хакында туганнарының һәм дусларының кайбер истәлекләре. - «Фатих Әмирхан турында истәлекләр» дигән китапта. - Казан, 1986, 91-97 нче битләр.
2. Карл Фукс. “ Казанские татары в статистическом и этнографическом отношениях”. -Казань, 1844 (36-37 биттән)
3. Айсылу Башкурова- Садыйкова.” Ислам һәм татар халык иҗаты”. -Казан, 2005 нче ел. 115 нче биттә. (Хәсән карый оныгы).
4. Архив материаллары.